Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы
Татар Баганалысы авыл җирлеге Советы

2023 елның 10 феврале № 30/3

КАРАР

«2022 елда шәһәр төзелеше эшчәнлеген гамәлгә ашыру үзенчәлекләре турында» 2022 елның 28 июнендәге 22/2 номерлы Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Татар Баганалысы авыл җирлеге советы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе закон актларының аерым нигезләмәләренең гамәлдә булуын туктатып тору турында» 2022 елның 19 декабрендәге 519-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Татар Баганалысы авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. «2022 елда шәһәр төзелеше эшчәнлеген гамәлгә ашыру үзенчәлекләре турында» 2022 елның 28 июнендәге 22/2 номерлы Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Татар Баганалысы авыл җирлеге советы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемендә «2022 елда» сүзләрен «2022 һәм 2023 елларда» сүзләренә алмаштырырга;

1 пунктның беренче абзацында «2022 елда» сүзләрен «2022 һәм 2023 елларда» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең торак пунктлары территориясендә махсус мәгълүмат стендларында яисә Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә, шулай ук Чистай муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендә урнаштырырга.

Татар Баганалысы авыл җирлеге
башлыгы _______________ Р.Р. Җәббаров